ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Россия Федерациясендә халыкның финанс белеме дәрәҗәсен арттыруга һәм финанс белемен үстерүгә ярдәм итү” проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәне раслау хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Предприятиеләрне реструктуризацияләү һәм финанс институтларын үстерү буенча коммерциячел булмаган фонд арасында “Россия Федерациясендә халыкның финанс белеме дәрәҗәсен арттыруга һәм финанс белемен үстерүгә ярдәм итү” проектын гамәлгә ашыру турындагы 2014 елның 24 июлендәге 01-01-06/17-194/605 номерлы шартнамәне расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 23 сентябре
№ 65-ТРЗ